Соңгы сүз туры килгән бала, «Миндә!» дип, тупны югарыкүтәрәһәм аны балаларның аякларына ыргыта. Аягына туптигән бала уеннан чыга. 3–5 бала «тотылгач», уен тәмам була.Кабатлап уйнаганда, тупны икенче юнәлештә җибәрәләр.


**Өрел, куык!**

Балалар түгәрәккә тезелеп басалар. Башларын алга ия төшеп, берсен икенчесе өстенә куйган йодрыкларына һава өрәләр – «куык кабарталар». Башларын турайтып, эчләренә һава алалар да яңадан, иелеп, «ф-ф-ф» дип, «трубка» эченәһава тутыралар (2 тапкыр кабатлана). Һәр өргән саен, бер адымартка атлыйлар (куык кабара бара). Шул рәвештә бу күнегү 2–3 тапкыр кабатлана. Аннан соң, бер-берсенең кулларынатотынган хәлдә, түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә артка чигенә барып, түгәрәкне киңәйтәләр:

Өрел, куык, зур булып,
Тик шартлый күрмә тулып;
Һаман да бул син матур –
Кабарынып тор да тор!

Җөмләнең ахыргы сүзләрен әйткәндә, куык (түгәрәк) зур булып җитешә.

*Бергәләп өйрәник*



***Куркынычсызлык кагыйдәләре***

***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

***(4-5 яшь)***

## Мәкальләр

*Аюдан курыксаң, урманга барма,
*Бүредән курыксаң, сарык асрама.
* Ике куянны берьюлы кумыйлар.
* Юлда йөрергә дә акыл кирәк.
* Урау булса да, юл яхшы.
* Юлга чыксаң, азыгың үзең белән булсын.

## Табышмаклар

* Авызы юк, борыны юк,
Тик бар аның өч күзе.
Урамдагы хәрәкәтне
Көйләп торадыр үзе.
(Светофор)
* Башыбыз бар, гәүдәбез бар,
Юк кул, аякларыбыз.
Балалар тотса куркабыз —
Яман шул якларыбыз.
(Шырпы)
* Сукмактан да чыгалмыйлар,
Бер-берсен дә уздырмыйлар,
Кызыл күзле ябалактан
Рөхсәт алмый кузгалмыйлар.
(Трамвай, светофор)
* Пожар турында ишеткәч,
Сигнал бирергә ашык.
Янгын гел көчәя бара,
Туктатып булмый ич һич.
Су гына сүндермәс аны,
Кирәк шул... (ут сүндергеч).
* Автомобиль, трамвайдан
Саклан, димен, бик сак бул!
Уйный торган урын түгел
Машиналар йөргән... (юл).
* Җәен, кышын, яз, көзен,
Иртән, кичен, көндезен
Телсез әйтәдер сүзен —
Ача-йома өч күзен.
(Светофор)

***Светофор— тәмлетамак?!***

Светофордан сорадым бүген:
– Нигә кып-кызыл
Синең бер күзең?
Елмаеп, миңа
Ул болай диде:
– Кызыл помидор
Ашаган идем...
Светофордан
Сорадым тагы:
– Икенче күзең
Нигә сап-сары?
Елмаеп, янә
Ул болай диде:
– Иртән лимонлап
Чәй эчкән идем
Сорамый тагы
Буламы түзеп:
– Нигә ямь-яшел
Өченче күзең?
Балкып елмайды
Һәм әйтте аннан:
– Ашаган идем
Ямь-яшел алма...
Шаярта ла ул –
Беләм ич инде!
...Шулай да торам
Ялмап иренемне.
ЛәбибЛерон

*Хәрәкәтле уеннар*

**Туп белән куышу**

Балалар түгәрәк ясап басалар. Түбәндәге сүзләрне әйтә-әйтә, тупны түгәрәк буенча җибәрәләр (бер-берсенә бирәләр):
Бер, ике, өч,
Дүрт, биш, алты,
Туп кемдә калды?
– Миндә!